СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

НУРЛАТ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА НУРЛАТСКОГО РАЙОНА.

*20 ноябрь, 1998 ел.*
*ҖОМГА*

*Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга.* *№ 132 (8289)* *Бәясе билгеләнгәнчә*

# ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘ. УЛ НИНДИ БУЛАЧАК?

***17 ноябрьдә Нурлатта җирле үзидарә мәсьәләләре буенча район семинары булып үтте. Балалар сәнгать мәктәбенең концерт залына җирле үзидарә Советлары җитәкчеләре, район активы, хакимият аппараты һәм халык депутатларының берләштерелгән Советы хезмәткәрләре, галимнәр җыелды.***







*Н.АЗИЗОВ фотолары.*

Очрашуны халык депутатларының Нурлат берләштерелгән Советы рәисе, хакимият башлыгы **Ф.С.СИБАГАТУЛЛИН** ачты һәм алып барды. Ул бүген сүз урыннардагы идарә тармакларын ничек итеп ныгыту һәм ул органнарга хуҗалык итү рычагларын үз кулларына ныклап [illegible]уда булышу, предпри[illegible]иеләр, оешмалар һәм учреждениеләрнең җирле үзидарә органнары белән үзара мөнәсәбәтләрен ныгытуда Россиянең кайсы регионнарының тәҗрибәсен (ә андый тәҗрибә Норильскидан алып Суздальга кадәр күп һәм төрле тупланган) нигез итеп алу турында барганлыгына басым ясады. Халыкны тормышчан әһәмиятле күп мәсьәләләр борчый: авылга табигый газ кертелгәнме, су, ут бармы, район үзәгенә автобус йөриме, авыл юллары төзекме, сакаллы төзелешкә әйләнгән клуб [illegible]айдалануга бирелерме?.. Боларның барысын да җирле властьтан сорыйлар, ә ул эшләргә акчаны каян алырга? Җирле үзидарәне алга таба үстерү программасын эшләүгә тәҗрибәле галимнәрне дә тартырга дигән фикергә киленде, бу кирәкле һәм мөһим идеяләрне тагын да уйлабрак гамәлгә кертергә мөмкинлек бирәчәк.

Академик **В.И.ПАТРУШЕВ** (Мәскәү шәһәре) Россия Федерациясенең дистәләгән регионының базарны "авызлыклау", төрле ведомствога караган объектларның яшәешен тәэмин итү, социаль программаларны гамәлгә ашыру буенча тәҗрибәләре турында конкрет мисаллар белән җентекләп сөйләде. Коры академик формада булмыйча, җанлы сөйләшү рәвешендә ясалган докладның икътисадый аспектлары киңәшмәдә катнашучыларда аеруча кызыксыну уятты. Җирле финанс мәсьәләләре әлегә законнар белән көйләнмәгән, нәтиҗәдә, мисал өчен, җирле үзидарә Советлары тарафыннан җыелган салымнар "өскә" күчерелә, ә социаль яктан аларның бер өлешен урыннарда калдыру гадел булыр иде. Бу түбәнге Советларның финанс эшчәнлеген оештырыр, аларга социаль сфераны тәртиптә тотарга һәм озак сроклы социаль программаны хәл итәргә мөмкинлек бирер иде. Шуңа күрә дә җирле финансны ныгыту - халыкның яшәешен тәэмин итүнең төп нигезе - соңыннан без әңгәмә корган җирле үзидарә Советлары рәисләре нәкъ менә шуны үз эшләрендә иң авырткан мәсьәлә буларак билгеләп үттеләр. В.И.Патрушев шулай ук финанс - кредит системасы, муниципаль банклар челтәре, кадрлар, җирле үзидарә Уставының сыйфат ягы мәсьәләләренә дә тукталды.

Муниципаль университет (Әлмәт шәһәре) проректоры, профессор **И.В.МАРТЫНЫЧЕВның** чыгышы җирле үзидарәнең фәлсәфи мәсьәләләренә багышланган иде. Бу мәсьәләгә иң яңа күзлектән чыгып караучылар да тарихи чагыштыруларны читләтеп үтә алмыйлар.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Советлар белән эшләү бүлеге мөдире **Л.В.ЛЬВОВА** җирле үзидарә органнары вәкилләренең октябрь - ноябрь айларында булып узган территориаль җыелышлары йомгаклары турында сөйләде. Аларның Чистайда узганында безнең нурлатлылар да катнашты һәм газетабызда бу хакта язылды инде. Территориаль җыелышларда кабул ителгән рекомендацияләрдә дәүләт вәкаләтләренең кайберләрен җирле үзидарә органнарына йөкләү, аларның хезмәткәрләренең статусы, җир өчен салымны түбәнге органнарга бирү һәм башка мәсьәләләр турында законнар кабул итү кирәклеге әйтелә. Л.В.Львова җирле үзидарәне тагын да үстерүнең кайбер мәсьәләләре буенча инде аерым законнар эшләнүе турында әйтте.

Киңәшмәдә әлләни дискуссия куермады. Әмма, сүз дә юк, ике якның әңгәмәсе килеп чыкты. Реформалар курсы тайпылышсыз, күп мәсьәләләргә искечә карашлар юкка чыга, тик яңа практика авырлык белән гамәлгә керә, ә яңа законнар тормыш артыннан өлгерә алмый дигән мәсьәләләрдә фикерләр уртак булды. Советлар саклана - авылда аларсыз эш бармый. Димәк, җирле үзидарәгә булышырга кирәк. Бу юлы инде дәүләт дәрәҗәсендә.

**Т.НАЗАРОВА.**



***Иң көнүзәк мәсьәлә***

## КЕМ АЛДАН АЯК КИЕНӘ, ШУЛ ГАЗГА ТИЕНӘ

Район хакимиятенең районны газлаштыру эшен ничек тә тизрәк тәмамлау мәсьәләсен көндәлек игътибар үзәгендә тотуы турында язып торабыз. Хакимият башлыгы үзе дә, аның урынбасарлары да ул мөһим эшне күз уңыннан ычкындырмыйлар. Әле узган атнада гына хакимият башлыгы урынбасары Н.Б.Мөлеков җирле үзидарә Советлары рәисләре һәм газлаштыру эшенә мөнәсәбәтле башка җитәкчеләр белән уздырган чираттагы киңәшмәдә быел башкарылган һәм гамәлгә ашырылырга тиешле эшләр, шул җөмләдән барлык якларның да бурычлары турында җитди сүз булды. Бүтәнчә мөмкин дә түгел, чөнки алга куелган программа гаять киеренке һәм аны вакытында башкарып чыгу да бик җитди мөнәсәбәт сорый.

**(Ахыры 2 нче биттә).**

## СӘБӘБЕ САЛЛЫ ИДЕ

Сишәмбе көнне Нурлат дәүләт орлык инспекциясе коллективы хезмәттәшләре - әйдәп баручы агроном В.И.Евдокимованы чын күңелдән куанычлы яңалык белән котлады. Эш шунда: шушы көннәрдә генә Валентина Ильиничнага Россия Федерациясе авыл хуҗалыгы министры урынбасары В.И.Алгинин имзасы белән Мактау грамотасы кайтты. Россиянең орлык контроленә 120 ел тулу уңаеннан иң лаеклы хезмәткәрләргә юлланган Мактау кәгазендә: "Авыл хуҗалыгы производствосында озак вакытлар һәм намуслы хезмәт, югары сортлы һәм чәчү сыйфатларына ия орлыклык һәм утырту материаллары фонды булдыруда шәхси өлеше өчен" дигән юллар бар иде.

26 ел инспекциядә эшләп, әйдәп баручы агроном дәрәҗәсенә ирешкән, иң төп йөкне тартучы Валентина Ильинична исә коллективның алыштыргысыз лидеры булса да, холкы буенча тыйнак, ипле, кешелекле булып кала белгән. Шуңа да коллектив әгъзалары үз хезмәттәшләре уңышына чын күңелдән шатланды, бу көнне аңа иң изге теләкләрен юлладылар.

## ИГЪТИБАР: ФОТОКОНКУРС!



Менә берничә ел инде балалар - яшүсмерләр үзәге каршында "Фотон" фототүгәрәге эшләп килә. Анда шәһәр мәктәпләреннән төрле яшьтәге балалар бик кызыксынып йөриләр. Безнең түгәрәктә шөгыльләнүчеләрнең хезмәтләре республика күләмендәге күргәзмәләрдә дә еш кына призлы урыннарны алалар дип горурланып әйтә алам. Менә теләүчеләргә үз осталыкларын күрсәтергә тагын бер форсат чыкты: бу юлы барлык фотоһәвәскәрләр дә 23 - 30 ноябрьләрдә балалар - яшүсмерләр үзәгендә балалар туризмының 80 еллыгына багышланган фотоконкурста катнаша алачаклар. Иҗат эшләрендә туристлар тормышына, походларга һәм ярышларга кагылышлы барлык төрледән - төрле хәлләр чагылдырылырга, районыбыздагы балалар туризмы ветераннарының фоторәсемнәре дә куелырга мөмкин. Фотосурәтләр аклы -каралы булса да, төсле дә, теләсә нинди үлчәмдә дә ярый. Сезнең һәр эшегезгә шат булачакбыз, ә җиңүчеләрнең фоторәсемнәре аерым билгеләп үтеләчәк, шул исәптән район газетасында да басылачак.

**С.ФАДЕЕВА.**

**Балалар - яшүсмерләр үзәге.**

## Республика сулышы

***** *Чаллы каласы "Россиянең иң матур шәһәре" бәйгесендә дүртенче урынны алды.*

*Ярышта Россия Федерациясенең өч мең ярымнан артык шәһәре катнашты. Шәһәр хуҗалыгын алып бару күрсәткечләренә караганда да Чаллыга тиңнәр табылмаган һәм ул иң яшел шәһәр буларак та игълан ителгән.*

***** *Парижда узган Халыкара эчемлекләр һәм минераль су ярминкәсендә "Булгарпиво" акционерлык җәмгыятенең "Яр Чаллы" суы иң яхшылардан дип билгеләнде. Ул халыкара сертификатка һәм алтын медальгә ия булды.*

## «ДУСЛЫК»КА ЯЗЫЛДЫГЫЗМЫ ӘЛЕ?

***1999 елның беренче яртысы өчен "Дуслык" ("Дружба", "Туслах") район газетасына язылу бәясе - 25 сум 20 тиен. Бөек Ватан сугышында катнашучыларга һәм инвалидларга, Әфган сугышында булучыларга, Чернобыль атом электр станциясендәге фаҗига нәтиҗәләрен бетерүдә катнашучыларга тиешле документлар нигезендә 50 процент ташлама ясала.***

*Иң көнүзәк мәсьәлә*

# КЕМ АЛДАН АЯК КИЕНӘ, ШУЛ ГАЗГА ТИЕНӘ

***(Ахыры. Башы 1нче биттә).***

Дөрес, быелның ун аенда газчылар киң колачлы эшнең шактый өлешен башкарып чыгарга өлгерделәр. Уртак тырышлык белән 114,43 километр, шул исәптән авылларда 105,5 км. газүткәргеч төзелде, шуның яртысыннан артыгы - поселокара газүткәргечләр һәм ул төр план авыл җирендә дә, Нурлатта да арттырып үтәлде, беренчесенең дә арттырылып башкарыласына ышаныч бар. Шушы чорда барлыгы 2414 фатир газлаштырылды, шуларның яртысы - авыл җирендә. Шәһәрдә быелгы план икеләтә диярлек үтәлде инде, авылларда да эшнең тукталып торганы юк. Бүгенге көндә 25 торак пункт тулысынча газлаштырылган, быел гына да 18 авылга газ бирелде һәм шуларның дүртесендә газлаштыру быел башлап, быел тәмамланды.

Подряд оешмалары арасында иң күп эш күләме элеккечә үк "Востокмонтажгаз" акционерлык җәмгыяте оешмалары өлешенә туры килә. 71 километрдан артыграк газүткәргеч сузып, алар бу төр еллык планны 161 процентка үтәделәр, 613 фатирны да газлы иттеләр һәм ел ахырына кадәр тагын 340лап гаиләне куандырырга ниятлиләр. "Газпромстрой" оешмасы фатирларны газлаштыру планын берьярым тапкырга, "Татгазстрой" ике тапкырдан күбрәккә башкарып чыктылар. Башка подрядчыларның да өлеше аз булмады. Тик аларның күпчелеге газүткәргечләр төзү буенча еллык программаны тутырудан ерак торалар әле.

Анысы - кем әйтмешли, алар намусында. Әмма газлаштыруның һәркайда да без көткән темпларда бармавында урыннардагы җитәкчеләрнең һәм халыкның үзенең дә гаебе бар. Тоткарлыкларның сәбәпләре күптөрле булса да, эш беренче чиратта акчага килеп төртелә. Көтәргә эшли торган заман узды һәм подрядчыларның йортларга газ бирү өчен алдан акчасын түләүне таләп итүләре урынлы. Газ уңайлыгына тиенергә теләге зур булган хуҗалар исәп - хисап ясауның күп мөмкинлекләрен табалар. Газ бер ел дигәндә кертелеп бетерелә язган Сәләнгеш һәм Зүзәй авылларында җирле үзидарә Советы җитәкчелегенең җан атып йөрүе дә, халыкның активлыгы һәм кызыксынучанлыгы да үзенекен итте - бу авылларда газчыларга түләү өчен симертелгән терлекләрне сатып акча эшләү юлын бик уңышлы кулландылар һәм хәзер утын - күмер мәшәкатеннән котылдылар. Тагын берничә авылда бар шундый мисаллар. Кызганычка каршы, акча түләү мәсьәләсен гел сузып килүчеләр дә байтак. Бер үк вакытта урыннардагы җитәкчеләрнең кайсылары заказчы буларак үзләренең бурычларын тиешенчә үтәп житкермичә эшне озакка сузалар. Аерым алганда, бу Елаур, Бикүле, Заречный авылларына кагыла, Чүлпанда да эшләр заказчы гаебе белән тоткарланып тора. Бикүле дигәндә, газ кертелә башлап та тәгәлләнмәгән Илюткино авылын да күздә тотабыз. Халыкның үз өйләренә газ бирүгә комачаулык итүче вак кына җитешсезлекләрне бетерү турында бердәй кайгыртмавы да борчый - кайбер урыннарда эш берничә метр торбаны буяп чыгу, кайда тәрәзәләргә форточкалар куюга терәлеп тора. Проект - смета документациясен кайгыртмаучылар да бар. Аерым алганда, нинди зур Мамык авылында бүгенгәчә берничә генә йортка тиешле документлар әзер булуы турында кабатларга туры килә. Сүз уңаеннан, кайбер заказчыларның, акча юклыкка сылтап, подрядчыдан башкарма документларны алырга ашыкмаулары да борчый. Ә бу бит - бик җитди мәсьәлә.

Әйткәнебезчә, ел ахырына кадәр башкарасы программа киеренке әле. Әмма, тырышканда, кимендә 3160 фатирны газлы итәргә мөмкинлек бар. Аерым алганда, Әлмәт, Төрнәс кебек зур авылларда шактый гына эш башкару каралган. Ел ахырына кадәр юл аркылы чыгу эшләрен башкарып, Богдашкино авылына да газ бирү бурычы куела. Тик, әлеге дә баягы, газ һәркемгә кирәк булган кебек, ул эшкә дә һәркем үзеннән соралган өлешне кертсә яхшы.

**Р.ГЫЙЛЬМЕТДИНОВ.**



*Агалы - энеле Николай һәм Михаил Микушкиннар "Үрнәк" КХАсында тырыш, техниканы әйбәт белүче нәселдән саналалар. Михаил Прокопьевич - мастерской мөдире булып эшли, бөтен техниканың төзеклеге өчен җавап бирә. Ә Николай Прокопьевич карамагында бер генә техника, әмма аның да бик кирәклесе, өстәвенә, искесе - экскаватор. Иске булса да аны эшләрлек хәлдә тоту бик мөһим икәнлеген аңлый ул, чөнки техникасы белән үз хуҗалыгында гына түгел, тирә - күрше КХАларда да эшләп алырга туры килә бит аңа. Ә Николай Прокопьевич эш дигәндә вакыт белән санаша торганнардан түгел, техниканы да әйбәт белә. Шуңа иске экскаваторның алыштыргысыз хуҗасына бер дә тик торырга туры килми.*

*Рәсемдә: "Үрнәк" КХАсы механизаторы Н.П.Микушкин.*

*Н.АЗИЗОВ фотосы.*

# МИРСӘЕТ СОЛТАНГАЛИЕВНЫҢ КАЙТУЫ

Сүзем яңа чыккан китап турында. Мирсәет Хәйдәргали улы Солтангалиев - шул китапның авторы.

Үзе дә, китабы да кайда булганнармы?

Үзе үтерелгән, язганнары, сөйләгәннәре тыелган, кешеләр күзеннән ераккарак яшерелгән. Билгеле инде: язмалары үтерүчеләрне фаш иткән, хөкем исә җәлладлары кулында булган.

Бүген аңа 106 яшь булыр иде. Нибары. Үз арабызда картаерга тиешле замандашыбыз югыйсә. Ә аның халыктан аерып алынуына, репрессияләнүенә - 75, һәлак ителүенә 58 ел. Китабында иректә нибары 31 ел яшәп калган кешенең 10 ел дәвамында язган хезмәтләре. Әлбәттә, табылган кадәресе, исән - сау сакланган хәтлесе. Китап шулай атала да: "Мирсәет Солтангалиев. Сайланма хезмәтләр. Избранные труды". Әйе, хезмәтләр безгә кайсы телдә килеп җиткәннәр, шул телдә басылганнар, ә М.Солтангалиев татарча да, русча да иҗат иткән, хезмәт иткән.

Мирсәет Солтангалиев - ул безнең, татарларның, 20нче гасыр тарихыбызда нык урын алган эшлеклесе, иң фаҗигале язмышлы улы.

Әле үзе юк ителмәгән чагында, 1923 - 1940 нчы елларда, 18 ел буена төрмә - лагерьларда газаплануы өстенә аны "син - безнең дошманыбыз" дип газеталар, китаплар аша кыйнаганнар. Әллә кайда әллә кемнәр түгел, үзебездә үзебезнең атаклыларыбыз, гадәтиләребез... Әйтик, яраткан шагыйребез Һади Такташ "Син - дошманым минем" ("партияле һәм партиясез солтангалиевчеләргә") дип язган. Кем ничектер, мин Мирсәет Солтангалиев хакында шуннан артыгын белә алмадым. "Мин"не "без" дип ишәйтә алабыздыр... Әле 90нчы елга кадәр КПСС дигән партия хакимияте тарафыннан ул "халык дошманы" итеп тотылды.

Без бит Солтангалиевның үз йөзен күрмәдек, үз тавышын, үз сүзен ишетмәдек. Соңгы елларда аның хакында языла тора, үз хезмәтләре дә дөнья күрә башлады. Һәм менә тагын, Татарстан Архив хезмәтенең 80 еллыгына "Гасыр" нәшрияты тарафыннан чыгарылган китабы белән ул безгә кайтты. Аның сүзләре, фикерләре, хөкемнәре, сурәтләре зинданнан котылды. Һәм менә аны каһәрләгән томнар белән янәшә аның томнары да урын ала.

Укыйк, аңларга тырышыйк аны. Ул - дөнья күләмендә билгеле кешебез. Чит - ятлар да аны дуслары итеп таныйлар. Үз кешебезне үзебезнеке итә алдыкмы әле? Безнең дә, бер халыкның да дошманы булмаган ул.

М.Солтангалиев үзенең халык дошманы булып түгел, халык улы булып кайтасын белгән. Аңлы гомеренең соңгы 18 елында, репрессия шартларында, ул туган халкына, дөнья халыкларына, чын коммунист партиядәшләренә үзенең фикерләрен тулырак калдыру җаен тапкан: сөйләп, әйтеп торып хөкемдарларыннан тикшерү эшләренә яздырган, үзе язган...

Шул хәзинәне безгә җиткерүчеләр, китапның төзүчеләре: тарих фәннәре кандидаты Илдус Гыйззәтуллин һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсе башлыгы Дамир Шәрәфетдинов.

Шул хәзинә безгә, халкыбызга барып җитсен иде. Аны үзебезнеке, халкыбызныкы итик.

***Хәмзә ЗАРИПОВ.***

***P.S. Китап түбәндәге адрес буенча сатыла:***

***420111, г. Казань, ул. Кремлевская, д. 2/6. Главное архивное управление при КМ РТ. Телефон: 38-77-70 факс: 38-77-60; бәясе 103 сум.***

***Банк реквизитлары:***

***редакция журнала "Эхо веков"***

***Банк КФАКБ "Ак Барс"***

***расч. счет 40603810745020002708***

***корр. счет 30101810000000000889***

***БИК 049205889***

***ИНН 1654023030.***

# ГАЗ БӘЛА КИТЕРМӘСЕН,

## ЯКИ ГАЗЛАШТЫРУ БУЕНЧА ТӨП КАГЫЙДӘЛӘР ҮТӘЛӘМЕ?

"Нурлатгаз" эксплуатация - җитештерү идарәсенең бер ел ярымлык яшәү дәверендә шәһәрне һәм районны газлаштыру буенча зур эш башкарылды. Барлыгы 85,44 км. җир асты һәм 98,1 км. җир өсте газүткәргечләре сузылды, авылларда 1551 йорт, ә шәһәрдә 1468 фатир газлаштырылды. Тик шунысы бар, кай урыннарда заказчылар газлаштыруның югары темплары артыннан өлгерә алмыйлар әле.

Әйтик, кайбер урында, өй эчендәге газ үткәргеч җайланмаларының төзелеше проектсыз алып барыла. Бусы - бер. Икенчедән, подрядчылар газүткәргеч һәм җайланмаларга монтаж ясыйлар, ләкин заказчылар (йорт хуҗалары) алар башкарган эшләр өчен түләүне тоткарлыйлар. Нәтиҗәдә беренчесе "Нурлатгаз" га башкару - техник документациясен (ИТД) тапшырмый, ә безнең андый йортка табигый газ җибәрергә хакыбыз юк. Мондый очракларда газны үз ихтыяры белән рөхсәтсез җибәрүчеләр бар. Мисал өчен, 1997 елның 3 нче мартында Синдряков урамындагы торак йортларга газ җибәрелә. "Сельхозтехника" АҖе подрядчысы белән исәп - хисап ясамаганга, әле бүген дә документацияләрен "Нурлатгаз" ЭПУсына тапшырмаганнар.

1997 елның 13 мартында Урта Камышлы авылында газ җибәрелә. Заказчы - Мичурин исемендәге КХА подрядчы - "Татспецстрой" РСУсы белән бүгенге көндә дә башкарылган эш өчен исәп - хисап ясамаган һәм, әлбәттә, ИТД да тапшырылмаган. Шуңа күрә бу авылның 44ләп йортында газ җибәрү "Газ хуҗалыгында иминлек кагыйдәләре"н тупас бозуга китерә.

Шәхси йорт хуҗаларының гамәлдәге газүткәргечкә рөхсәтсез ялгану өчен чит кешеләрне эшкә тартулары өченче сәбәп булып тора.

1998 елның 13нче октябрендә Островский һәм Кутузов урамнарында 50 торак йортка газ килү туктатыла. Кутузов урамында яшәүче гражданин И. газ кертүчеләр яллый (кемнәр икәнлеген әйтми). Тегеләре эшермәне ябып, рөхсәтсез - нисез аның торбаларын газүткәргечкә ялгыйлар.

Фатирларда газ колонкаларын рөхсәтсез кабызу очраклары да борчый безне, чөнки Нурлатның байтак кына йортларында проект буенча газ колонкалары кую каралмаган, аерым алганда, колонка өчен төтен юллыклары ясалмаган. Шуңа күрә фатир хуҗалары колонканың төтен торбаларын җилләткеч каналларга тоташтыралар, нәтиҗәдә өстәге яки аскы катта урнашкан фатирларда ис газы белән агулану барлыкка килергә мөмкин.

Газүткәргеч челтәрләренең автотранспорт, төзелеш техникасы белән зарарлануы да зур куркыныч тудыра. 1997 - 98 елларда шундый 9 очрак исәпкә алынды.

Быелның гыйнвар аенда 547нче ПМКның битум ташучы машиналары Ленин урамында газүткәргечкә зыян китерәләр. 8 майда шул ук оешманың йөк ташучы машиналары Завод тыкрыгында 30 метр газүткәргечне зарарлыйлар.

10 апрельдә "Әлмәт" ПМКсы полиэтилен үткәргечен өзәләр, нәтиҗәдә Абрыскино авылында яшәүчеләр бер атна җылысыз утыралар.

26 сентябрьдә Салдакай авылында А.Андреев КамАЗ машинасы белән 400 метр газүткәргечкә зыян китерә. Ә 7 ноябрьдә шундый ук хәлне МТЗ - 80 тракторы тракторчысы Ф.Сәгыйров Кәкре Атау авылында кабатлый - ул 300 метр газүткәргечне өзә. Нәтиҗәдә бу авылның 40тан артык йорты әле бүген дә газсыз утыра.

Төзү - монтаж эшләренең сыйфаты да канәгатьләнерлек түгел. Бусы - алтынчы сәбәп.

1997 елның 8нче декабрендә Фома авылында диаметры 100 мм.лы газүткәргечнең 6 ялганган урыны ярылып чыга. Быелның февралендә Ленин урамында 4 җирдә җөй шартлый, ә октябрьдә Андреевка авылында диаметры 159 мм.лы газүткәргеч шартлый. Соңгысында сыйфатсыз ябыштырылган җөйләр аеруча күп, 50- ләп йорт шуңа күрә газсыз торалар. Югарыда әйтелгән объектлар буенча эшләрне Димитровград шәһәреннән "Гидромонтаж" АҖнең 14нче МСУсы башкарган.

Алда әйтелгән кагыйдәләрне бозу очраклары өчен җаваплы кешеләргә карата административ чаралар күрелде.

Бер уңайдан "Сельхозтехника" АҖ һәм Мичурин исемендәге КХА җитәкчеләренә шуны кисәтәсе килә: тиешле срокта әлеге җитешсезлекләр бетерелмәсә, газ җибәрү туктатылачак.

Шул ук вакытта Нурлат районында һәм шәһәрендә яшәүчеләр игътибарын да газлаштыруның бәяләренә юнәлтәсем килә: быел бер торак йортны яки фатирны газлаштыруның бәясе 1,5 - 2,5 мең сум торса, киләсе елда ул 6 мең сумга кадәр җитәчәк.

**Н.МОКРИКОВ,**
**"Нурлатгаз" ЭПУсының баш инженеры.**

# ЛЕГЕНДАГА ТИҢ ГОМЕР

## Юбилейлар

### Якташыбыз Фалес Әхәт улы Вәлиевка 60 яшь

Фалес Әхәт улы Вәлиев 1938 елның 30 сентябрендә Татарстанның хәзерге Нурлат районы Кычытканлы авылында дөньяга килгән. Ике яше дә туларга өлгерми, әтисе сугышта хәбәрсез югала. Шуннан соң ир-ат тәрбиясен аңа бабасы Минневәли бирә. Ятимлек кырыслыгы егетне кечкенәдән үз көченә таянырга өйрәтә. Үзен кыерсытырга юл куймый, гайрәтле, төпле булып үсә.

Авылда техниканың ролен аңлап, хәзерге Спас районында механизация училищесында комбайнчылыкка өйрәнеп кайта. Бөтен таянычы бер бабасы булганга, колхозда ирләр белән беррәттән эшләргә туры килә аңа. Шуның белән бергә ул укырга да омтыла. Авылдан беренчеләрдән булып Казан дәүләт университетына кергән һәм аны тәмамлаган кеше - Фалес Вәлиев. Казанга килеп укый башлагач,аңа яшьли өйрәнгән һөнәрләре бик ярап кала. Үзе уку белән беррәттән ул ДОСААФ оешмасы каршында мотоциклчылар укыта. Курсташлар арасында укытучылар да шактый булып, көндезләрен университет галимнәре Фалеска лекция укый, кичләрен рольләрен алмашалар - ул аларны техника серләренә өйрәтә. Шуңа да аңа гади студент итеп кенә карамыйлар. Дәрәҗә, абруе башкаларга караганда шактый зур була аның. Өстәвенә, чибәр, бик матур итеп гармунда уйный. Кызлар да яраталар мондый егетне.



Минзәлә кызы Кларане гомерлек яр итеп сайлый Фалес. Студент дуслары, укытучылары җыелып бик матур туй уздыралар. Шуннан гомерләре буе бер-берсенә таяныч булып яши алар. Фалес көне - төне эштә. Клара мәгариф өлкәсендә эшләү белән бергә бөтен өй йөген тарта, балалар тәрбияли. Кызлары Фәридә, малайлары Фәрит, Алмаз үзләре гаилә корып, бик матур яшәп яталар.

Хезмәт юлын комбайнчы ярдәмчесе булып башлаган Фалес университет бетереп Зәйгә кайткач укытучы, директор булып эшли.

Хуҗалык эшенә сәләте белән ачылып китә. Югары Пәгәче авылында таш мәктәп төзетә. Аның турында газеталарга язалар. Халык ярата үзен, район җитәкчеләре дә игътибардан читтә калдырмыйлар. Һәм менә 1971 елда Фалес Вәлиевны районның иң зур хуҗалыгы "Якты йолдыз" колхозы рәисе итеп сайлыйлар. Сигез авыл кергән колхозны Зәйнең иң алдынгы хуҗалыклары рәтендә алып бара Фалес Әхәтович.

Халык турында кайгырткан җитәкчене ул авыл кешеләре бүген дә сагынып, яратып искә алалар. Аннан районның авыл хуҗалыгы идарәсе башлыгы, Саратов югары партия мәктәбендә уку, халык контроленең шәһәр комитеты рәисе булып эшләү.

Кайда гына эшләсә дә, дөбердәтеп эшли Фалес Әхәт улы Вәлиев. Масштаб белән, киң колач белән эшли. Әмма гомерлеккә крестьян тормышын сайлый. 1986 елда партиянең шәһәр комитетының бюро утырышында ит җитештерү буенча район хуҗалыкара берләшмәсенең эше карала. Нык бетешкән бу хуҗалыкка яңа, көчле җитәкче кирәк дигән фикергә киләләр. Әмма кайдан аласың андый кадрны? Шулвакыт Ф.Ә. Вәлиев, бюроның башка әгъзаларын бераз аптырашта калдырып, үзен әлеге берләшмәгә директор итеп билгеләүләрен сорый. Җылы урыннан артта калган хуҗалыкка китү ул вакытта күпләргә аңлашылмый билгеле.

Тик үзенең дөрес адым ясаганлыгын Ф.Ә. Вәлиев бик тиз таныта. Район хуҗалыкара берләшмәсе, соңрак "Зәй" совхозы, бүген "Заман" авыл җитештерү кооперативы көн артыннан көн (үзенең) матур эшләре белән куандыра. Ит җитештерү 2 мәртәбәгә арта, игеннәрнең уңышы узган ел гектарыннан 50 центнердан артык тәшкил итте. Һәр елны җитәрлек күләмдә терлек азыгы хәзерләнә. Бетүгә юл тоткан авылларга икенче гомер иңде: асфальт юллар төзелде, газ кертелде, йөзләгән йорт-фатир, социаль-көнкүреш, җитештерү объектлары төзелде. Иң мөһиме, халык эш белән тәэмин ителеп, вакытында хезмәт хакы алып, матур итеп эшли, яши башлады.

Ф.Ә.Вәлиевның иң төп сыйфаты - аның эшкә бирелгәнлеге, намуслы хезмәте. Армиядә танкист булып хезмәт иткән елларында алган рәхмәтләрдән башлап һәр эшләгән эшендә иң дәрәҗәле бүләкләргә ирешкән кеше ул. Хезмәт кенәгәсендә генә дә андый 52 язма бар. Ф.Ә.Вәлиевның "Хезмәт Кызыл Байрагы" ордены (1973), "Халыклар дуслыгы" ордены (1993),Татарстанның һәм Россиянең атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре дигән мактаулы исемнәре, (1990) Татарстан Республикасының Мактау Грамотасы, үзәк органнарның күпсанлы мактау кәгазьләре, "Халык мәгарифе отличнигы" билгесе һәм күпсанлы башка бүләкләре аның ил, халык алдындагы зур хезмәтләре турында ачык сөйли.

Аның турында дәүләт эшлеклесе, зур политик буларак та әйтергә кирәк. Ул бүген Татарстанның Дәүләт Советы депутаты, аңа хәтле Зәй район Советы рәисе булып эшләде. Бу киеренке һәм тулы канлы күпкырлы эшчәнлеге чорында ул Татарстанның суверенитетын яклаучыларның алгы сафында булды, татар телен һәм мәдәниятын үстерүгә зур өлеш кертте. Шуның өчен Зәй районы һәм Зәй шәһәре хакимияте башлыгының Сөббух Рафиков исемендәге бүләген алды (1993).

Ф.Ә.Вәлиевның дуслары бик күп, дуслыкның кадерен белә торган кеше ул, республиканың, Зәйнең бихисап күренекле кешеләре, шул исәптән язучылар, галимнәр, журналистлар аның йөрәк җылысын тоеп даими аралашып яшиләр.

Фалес Әхәт улы Вәлиев - легендар кеше. Ике тапкыр йөрәгенә операция ясатып, теге дөньяларны кичеп кайтуына һәм 60 яше тулуына карамастан, ул һаман көнне - төнне, ялны белми эшли. Республиканың авыл хуҗалыгында андый җитәкчеләр, мөгаен, бармак белән генә санарлыктыр. "Халыкка хезмәт итү миңа көч бирә", - ди татар халкының чын мәгънәсендә каһарманы үзе турында.

**Рәис Габсәлам улы НӘҖИПОВ,**

**Зәй районы хакимияте башлыгының урынбасары.**

**Рәсемдә: Ф.Ә.Вәлиев гаиләсе белән. 1978 ел.**

---

# ККМ: ҺӘР ЯК ҮЗЕНЧӘ ХАКЛЫ

**АКТУАЛЬ**

Бу көннәрдә Нурлат эшмәкәрләре - сәүдәгәрләре умарта күчедәй гөжләп алдылар. Сәбәбе дә бар иде. 15 ноябрьдә контроль - касса аппаратларын алуга бирелгән срок чыга, ә ансыз базарда сату тыела, инде саткан очракта да бу тупас рәвештә кагыйдә бозу буларак каралачак һәм зур күләмдә штраф салыначак иде. Әмма бу таләп күпләргә ошамады. Бердән, бу аппаратларның бәясе кыйммәт (ККМнарга хезмәт күрсәтү үзәгендә алар 3.600 сум тора), икенчедән, алар кышкы чорда файдалануга яраксыз: аларны чыгаручы завод машиналарның ышанычлы эшләвен 10 градус салкынлыкка кадәр генә гарантияли (дөрес, үзәк җитәкчесе С.П.Смирнов 20 градус салкынлыкка да чыдый торганнарын алып кайтырга вәгъдә бирә). Өченчедән, аппарат алган һәр кеше аны югарыда телгә алынган үзәккә исәпкә куярга, димәк, аңа хезмәт күрсәтү өчен янә түгәрәк кенә сумманы түләргә тиеш була. Бары шуннан соң гына сатуга рөхсәт бирелә.

- Без мондый чыгымнарны күтәрә алмыйбыз, бу бит безнең өчен чын бөлү! - 12 ноябрь көнне салым инспекциясе начальнигы бүлмәсенә җыелган эшмәкәрләр бертавыштан шулай тәкърарладылар. Аңа кадәр үз зарларын 173 эшмәкәр имза куеп, район хакимияте, салым инспекциясе һәм редакция адресына юллаган иделәр. (Алар барлыгы 300ләп исәпләнәләр бездә). Хаттан бераз өзек китерәм.

*"Базарга без яхшы тормыштан килмәдек. Безнең арада ике дистәләп кенә пенсионер, калганнары - яшьләр һәм гаиләле эшсезләр. Без һәр айда сәүдә хокукы өчен лицензиягә (базарга атнага 2-3 көн генә чыксак та), пенсия фондына, сырхауханә кассасына, район финанс бүлегенә (12 процент иде, ә хәзер күпчелек товарларга 15 процент) түлибез. Базарда саткан өчен безгә көненә 15 сум һәм саклык камерасы өчен 10 сум түләргә туры килә. Башка шәһәрләрдә базарларда эшмәкәрләр атна уртасында ял көннәренә караганда азрак түлиләр, бездә түләү бертөрле. Ә бит безнең базардан бер әйбер дә сатмыйча кайткан көннәребез дә була.*

*Кайбер эшмәкәрләрнең барлык товары да 1 - 2 меңнән артмый һәм аларның касса аппараты алырлыклары гомумән юк. Алар, базардан баш тартып, яшәү чарасыз калырга мәҗбүр булачаклар. Шулай итеп, пособиегә өметләнүче эшсезләр саны тагын арта төшәчәк. Без урамда яки электр уты кертелмәгән салкын складта (кием - салым базары) сату итәбез. Мондый шартларда аппарат эшләмәячәк. Безгә нәрсә эшләргә?"*

Салым инспекциясендә нәкъ шушы соңгы сорау буенча фикер алышу булды да. Эшмәкәрләр, ә аларның күбесе хатын - кызлар, "челнок" бизнесы башланган көннән алып җыелган җан ачыларын, арыганлыктан, бер кисәк ипигә акча эшләү мөмкинлеген югалту куркынычыннан туган ачуларын бу көнне берьюлы бушаттылар бугай. Алар ККМ кертүдән түбәндәге сәбәпләр буенча баш тарттылар.

*- Хәзер без һәммәбез даруга гына эшлибез. Һәрберебездә хроник чирләр бар, күбебез яман шештән операция үтте һәм шуңа карамастан, базарда басып торуыбызны дәвам итәбез,чөнки башка чарабыз юк.*

*-Без товарларга өстәмәне аз-10 процент кына куябыз,шунлыктан халык товарны бездән ала.Без китсәк,мохтаҗлар кая барырлар?*

*-Безнең күбебез болай да бурычка чумган,ә касса аппараты безнең өчен бик кыйммәтле уенчык.Өстәвенә,ул әле гамәлгә дә яраксыз.*

*- Бу тәртипне язга таба кертсәләр бер хәл иде...Безне кем дә булса якларга тиештер бит инде.Без бит тиешлене бюджетка түләп торабыз.*

Шул ук вакытта эшмәкәрләр салым инспекциясе начальнигы **Г.МИННЕГАЛИЕВ** сүзләре белән дә килешми булдыра алмадылар: "Без, җирле органнар, югары органнарның вакләп сатуга касса аппаратлары кертү турындагы күрсәтмәсен үтәми кала алмыйбыз."Аннан соң Гомәр Әхмәтвәлиевич РФ Хөкүмәтенең 1993 ел,30 июль карарына яраклаштырып халык белән исәп-хисапны ККМсыз алып барырга хокуклы аерым категория затларны һәм очракларны санап чыкты.Безнең эшмәкәрләр өчен бары бер генә - электр уты сүнгән очракта гына ККМсыз сатарга рөхсәт итүче пунктның гына файдалы булуы ихтимал иде.Бу очракта да алар сатып алучыларга РФ Финанс министрлыгы тарафыннан расланган форма буенча квитанция бирергә тиешләр.

*(Ахыры 4нче биттә).*

### РЕСПУБЛИКАНЫҢ КЫСКА СРОКЛЫ ОБЛИГАЦИЯЛӘРЕН КАПЛАУ ТӘРТИБЕ

***Министрлар Кабинеты юридик затларның Татарстан Республикасының кыска сроклы облигацияләре капланганнан соң алган акчаларын файдалану тәртибе турындагы положениене раслады.***

Анда юридик затларга облигацияләре каплану нәтиҗәсендә алган акчаларын агымдагы салымнарын, республика бюджетына һәм бюджеттан тыш фондларга булган бурычларын, шулай ук аренда хакын һәм дәүләт милкен реализацияләгән өчен, предприятиеләрнең акцияләре дивидендларын түләүгә тотарга рөхсәт ителә.

Моннан тыш, Татарстан Дәүләт милке белән идарә итү комитетына 20 ноябрьгә кадәр Министрлар Кабинетына юридик затларның республика кыска срокы облигацияләре каплануднан алган дәүләт милкен, акцияләрен (өлешләрен, пайларын) акча исәбенә реализацияләү тәртибе турындагы положениене раслауга кертү бурычы йөкләнде.

Шуннан соң юридик затлар кулындагы республика кыска срокы облигацияләрен сатуның икенче этабы башлана.

**Министрлар Кабинетының матбугат үзәге.**

# ККМ: ҺӘР ЯК ҮЗЕНЧӘ ХАКЛЫ

**(Ахыры.Башы 3нче биттә).**

Безгә калса, бу очракта ТР Дәүләт салым инспекциясенең 27.05.98 елгы аңлатмасы игътибарга лаек:"Халыкка ваклап сату челтәре аша сату контроль-касса аппаратлары кулланып алып барыла. Моңа искәрмә булып кул арбаларыннан,сыешлыклардан (сыра,квас, сөт,керосин),лотоклардан, кәрзиннәрдән сату санала. Моннан тыш, ККМ кулланмыйча сату итүгә хокук бирүче мәҗбүри нәрсә булып *сәүдәнең күчмәлеген* характерлаучы сыйфат санала:кул арбаларыннан, кәрзиннәрдән,лотоклардан сату". Югарыда телгә алынган сыйфатларның берсе генә булмаганда да ККМ куллану мәҗбүри икәнлеге ассызыклап әйтелә.

Бирелдә үк катнашкан прокурор ***А.П.ЕФГРАФОВка*** сорау бирелде: касса аппараты кулланмау ничек каралачак? Җавап: административ хокук бозу буларак, өстәвенә, һәр тәртип бозу аерым очрак итеп. Прокурор, үз чиратында, килеп туган хәлне җирле властьлар дәрәҗәсендә генә хәл итеп булмавын тагы бер кат ассызыклады. Бәлки, зур армия эшмәкәрләр тавышын югарыда ишетерләр...

Бу дәлилләр эшмәкәрләрне бераз тынычландыргандай итте. Әмма алар бирешмәскә, үз хокукларын ничек тә якларга дигән ният белән таралыштылар.

**P.S. Язма газетага әзерләнгәндә, салым инспекциясенә телдән генә булса да Казаннан 1999 елның 1 гыйнварена кадәр контроль - касса аппаратларын кертүне тоткарлап тору турында әмер килде. Әмма аның шарты да бар: калган арада хуҗалар касса аппаратларын куллану өчен мөмкинлек биргән эш шартлары тудырырга тиешләр. Шулай итеп, эшмәкәрләргә үз мөмкинлекләрен үлчәү өчен, ә җаваплы кешеләргә эшмәкәрләр мәнфәгатенә суккан бу таләпне йомшарту һәм халык мәнфәгатен яклау буенча чаралар күрергә вакыт бирелде. Соңгылары өчен хәзерге шартларда да базар прилавкалары төзелеп бетмәгән капитализмның бердәнбер уңай билгесе булып саналалар.**

**Д.ТӘМАЕВА.**

***Белмәдек димәгез***

# САКСЫЗЛЫКТАН ТАГЫН БӘЛА

Быел мең бәланы җиңеп "Сельхозтехника" микрорайонында яшәүчеләрнең өйләренә җылы бирелде. Бу җәһәттән Нурлат җылылык челтәренә дә шактый эш башкарырга туры килде. Тик, кызганычка каршы, бу вакыйгага бәйле рәвештә безнең предприятие яңа проблемага тарыды: халык өйләренең җылынуына шатланса да, белепме - белмичәме, җылылык системасына зур зыян китерә башлады - системадан килгән җылы суны рәхәтләнеп файдаланалар. Безнең исәпләүләр буенча, бу участокта тәүлеккә 80 куб су югалып тора. Әгәр алга таба да шулай була калса, торбаларны тутырырга су җитми башлаячак, нәтиҗәдә микрорайонның тагын суыкта утырып калуы ихтимал.

Системада суның югалуы НПТСка матди яктан зыян китерә: шул суны җылыту өчен күпме газ, электр уты тотыла, торбаларына зыян китермәү өчен салынган тоз әрәмгә китә. Анналары системадагы төрле кислоталы кушылмалар салынган суны файдалануның кеше сәламәтлегенә зарарлы булуын тагын бер кат искәртеп үтү дә әһәмиятле. (Бу хакта без газетада язган идек инде). Күбесендә җылылык системасы краны салкын су белән янәшә урнашканлыктан, җылы суның эчә торган су белән катнашу куркынычы да бар. Моннан төрле авырулар килеп чыгуы ихтимал.

Йомгаклап, тагын бер кат кисәтәсе килә: без бу микрорайонда, ягъни Тельман, Синдряков, Гыйматдинов, Степан Разин урамнарының 2нче котельнядан ягыла торган йортларында даими рейдлар оештырачакбыз һәм гаеплеләргә карата административ җәза ысулларын кулланачакбыз. Әмма алга таба системада суның югалмавы халыкның үз файдасына икәнлеген аңларлар дип өметләнәбез.

**Ф.ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА,**
**НПТС инспекторы.**



*Н.АЗИЗОВ фотоэтюды.*

***Файдалы киңәшләр***

## БӘРӘҢГЕНЕҢ БӘРӘКӘТЕ



* ***Ә**гәр суга 3 - 4 кисәк сарымсак салсаң, бәрәңге тәмлерәк булып пешә.*

* ***Б**ераз гына чәй содасы салсаң, бәрәңге кәтлите кабарып торыр.*

* ***Ч**икмәнле бәрәңге пешергәндә ярылмасын дисәгез, суга берничә тамчы серкә тамызыгыз.*

* ***Ә**гәр пешергәндә суга бер чәй кашыгы лимон согы һәм ике кисәк шикәр салсаң, иске бәрәңге каралмый һәм тәмлерәк була.*

* ***Б**әрәңгене әкрен утта пешерегез. Юкса ул тыштан пешә һәм изелә башлый, ә уртасы пешеп бетмәгән көе кала.*

* ***Ә**гәр кәстрүлгә аз гына тозлы кыяр яисә кәбестә суын салсаң, бәрәңге изелмәс.*

* ***Ө**шегән бәрәңгенең тәмсез исеннән котылу өчен, аны аз гына салкын суда тотарга һәм аннары бер чәй кашыгы серкә кушылган кайнап торган суга салырга кирәк.*


## Экспресс - үзәк товарлар һәм хезмәтләр тәкъдим итә:

- компьютерлар һәм оргтехника (ксерокслар, факслар һ.б.)
- персональ ЭВМнарга һәм оргтехникага комплектлаучы һәм тотыла торган материаллар
- локаль хисаплау челтәрләрен ахыргача урнаштырып бирү
- компьютерлар һәм оргтехникага гарантия чорында һәм аннан соң хезмәт күрсәтү
- персональ ЭВМ һәм оргтехниканы ремонтлау һәм заманчалаштыру
- **көнкүреш аппаратуралары** (телевизорлар, аудио - һәм видео магнитофоннар, видеокамералар, музыкаль үзәкләр һ.б.) ремонтлау
- ксерокүчермәләр алу хезмәте (А4 форматы)
- **текстлар җыю һәм бастырып бирү**
- персональ ЭВМнарда сәгатьләп эшләү мөмкинлеге
- фототасмаларны ачыгайту һәм төсле фотолар ясау (10 x15 форматлы)
- документларга мизгел эчендә 2,5 x 3,5 һәм 3,5 x 4,5ле аклы - каралы һәм төсле фотолар ясау
- фототоварлар (тасмалар, батареялар, альбомнар, фотоаппаратлар һ.б.)
- техник һәм матур әдәбият.

***Шартнамәләр төзи:***

- **персональ ЭВМнарга техник хезмәт күрсәтүгә**
- **программалар белән тәэмин итү һәм хезмәт күрсәтүгә**
- **махсус багланышлы программалар эшләү һәм аларны кертүгә.**

*Экспресс - фото үзенең клиентлары игътибарына фотосурәтләр ясауга 1998 елның 1 сентябренә кадәр бирелгән заказларның 1 декабрьгә кадәр иске бәя белән (бер фото 1сум 50 тиен) җибәрелүен җиткерә.*

**Республика НИОКР фондының терәк предприятиесе НИОКР эшләү, рәсмиләштерү һәм кулланылышка кертү буенча барлык хезмәтләрне дә күрсәтә.**

*Аксеновның Бизнес Мәктәбе Казан филиалы түбәндәге курсларда укырга тәкъдим итә:*

- Персональ ЭВМ (Windows,Ofisse 97) операторлары
- BASIC телендә программалау нигезләре
- FOXPRO телендә программалау нигезләре
- PASCAL телендә программалау нигезләре
- инглиз теленә өйрәтү

Нурлат шәһәрендә Мәктәп ур., 8 адресы буенча Экспресс - үзәккә иртәнге 8дән кичке 6га кадәр мөрәҗәгать итәргә (төш вакыты көндезге 1дән 2гә кадәр).

Белешмәләр өчен тел.: 5-37-51


## КОТЛЫЙБЫЗ!

Колбай Мораса авылында яшәүче **хөрмәтле тормыш иптәшем, кадерле әтиебез Илгиз Харрас улы Ибраһимовны** 60 яшьлек юбилее белән ихлас күңелдән тәбриклибез.



Һәлакәтләр сине читләп үтсен,
Күңелләргә кайгы тулмасын.
Ходай сиңа озын гомер бирсен,
Шатлыкларның чиге булмасын.

**Изге теләкләр белән тормыш иптәшең, кызларың, улың, киленең, оныкларың.**


## БЕЛДЕРҮЛӘР

### САТАБЫЗ

**Йорт һәм ванна.** Тел.: 5-10-60.

***

**Өч бүлмәле фатир, УАЗ - 452.** Тел.: 5-47-77.

***

**Красноармейская урамында (тимер юл котельнясы ягында) бер катлы йортта ике бүлмәле фатир, 1998 елгы, "коралл" төсендә ВАЗ - 2110.** Тел.: 5-19-06.

***

**Туй күлмәге.** Тел.: 2-19-71.

### САТАБЫЗ, АЛМАШТЫРАБЫЗ

**ВАЗ - 2101, кыйммәт түгел. Яки онга, шикәр комына алмаштырабыз.** Тел.: 5-38-64.

***

**Чанада гараж, капкалар, аккумуляторга кислота, торбалар, УАЗ - 452гә алгы пыяла. Яки азык - төлеккә алмаштырыла.** Тел.: 2-26-28.

***

**ВАЗ - 21011. Йортны - өч яки ике бүлмәле фатирга.** Тел.: 5-14-85.

### АЛМАШТЫРАБЫЗ

**Өч бүлмәле фатирны - ике һәм бер бүлмәлеләргә яки ике берәр бүлмәлегә.** Тел.: 5-11-58.

### ТӨРЛЕСЕННӘН

***Җаваплылыгы чикләнгән "Коопзаготпром" җәмгыяте халыктан:***

- килограммын 12 сумнан сыер ите, 13 сумнан дуңгыз ите,
- 1нче сортын килограммын 4 сум 50 тиеннән, 2нче сортын 3 сум 60 тиеннән, 3нче сортын 2сум 70 тиеннән мөгезле эре терлек тиресе,
- 1нче сортын 10 кв.дм 2 сумнан, 2нче сортын 1сум 70 тиеннән, 3нче сортын 1 сумнан вак терлек тиресе,
- халыктан һәм оешмалардан килограммын 20 тиеннән, мәктәпләрдән 25 тиеннән тотылган кәгазь сатып ала.

***

**"Новинка" кибете яңа ел бүләкләренә заявкалар кабул итә.** Тел.: 5-39-39.

***

**Кызыл төстәге ике яшьлек тана югалды. Аның кайдалыгын белүченең Торнояс авылында Еремеевка хәбәр итүен сорыйбыз.**

***Саклык банкының хөрмәтле клиентлары!***

***Сезгә 1998 елның 16 ноябрендә яңа төр - "Россия Саклык банкының яңа ел вклады" һәм " Россия Саклык банкының яңа ел вклады - плюс" дигән кертемнәр булдырылуын җиткерәбез.***

***"Россия Саклык банкының яңа ел вклады" вкладына кертемнең минималь суммасы сумнарда 300 сум, чит ил валютасында - 100 АКШ доллары. " Россия Саклык банкының яңа ел вклады - плюс" вкладына кертемнең минималь суммасы сумнарда 10000 сум, чит ил валютасында 3000 АКШ доллары.***

***Сумнардагы һәм валютадагы кертемнәр буенча түбәндәге процент ставкалары билгеләнде:***

***- "Россия Саклык банкының яңа ел вклады"нда - сумнарда еллык 40 процент, валютада еллык 9,7 процент.***

***- " Россия Саклык банкының яңа ел вклады - плюс" вкладында- сумнарда еллык 42,0 процент, валютада еллык 10,2 процент.***

Белешмәләр өчен тел: 2-25-83, 2-21-21.

РФ Үзәк банкының № 1481 генераль лицензиясе.



МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА**

**Учредительләр: Нурлат район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.**

**"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.**

**Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Нурлат шәһәре, Карл Маркс урамы, 19.**

**Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм җаваплы сәркәтип - 2-18-67, авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар, хатлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия,реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.**

***Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.***

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясендә офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2361 данә. 4401